## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Плетени торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**02 ноябрь, 2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәгә 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2020 елның 02 ноябрендә 17 сәгатьтә, булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезҗе авыл җирлегенең Плетени авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 45 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -27, бу 60 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" позициясе өчен гражданнар җыенында 27 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:
1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Плетени авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.
2. «Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең Плетени авылы территориясендә даими яшәү

у һәм  яшәү урыны буенча теркәлгән  һәр балигъ булган  кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье   авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Подберезье  авыл җирлеге Башлыгы   О.М. Емельянова